ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«08» июня 2021 ел № 94-р

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрен комплектлау комиссиясе составын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрен комплектлау тәртибе буенча тәкъдимнәр турында» Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 8 августындагы 08-1063 номерлы хаты, Татарстан Республикасы “Әгерҗе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрен комплектлауның бердәм тәртибен билгеләү һәм үтәү максатларында: Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрен комплектлау комиссиясе составын расларга (кушымта итеп бирелә).

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мәгариф идарәсенә «Мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрен комплектлау тәртибе буенча тәкъдимнәр турында» Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 8 августындагы 08-1063 номерлы хаты, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына керү турында гаризалар кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрен комплектлаштыруны оештырырга.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрен комплектлау комиссиясенә 1 июньнән 31 августка кадәр чорда мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен комплектлау эшен башкарырга.

3. Әлеге «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
08.06.2021 № 94-р
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрен комплектлау комиссиясе составы**

1. Баженова Ольга Алексеевна – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, **комиссия рәисе**;
2. Сафиуллина Вәсилә Гарәфетдиновна - «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы, **комиссия рәисе урынбасары**;

**Комиссия әгъзалары:**

3. Йосыпова Аида Наилевна - «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгының методик эш буенча урынбасары;
4. Кәлимуллина Ләйсән Рамилевна - «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе методисты;
5. Зиновьева Ландыш Илфаровна – «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе баш белгече;
6. Шурманова Гөлнара Ринатовна - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренен «Алтын ачкыч» 1 нче балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдире;
7. Яппарова Лилия Дөфәровна - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең «Бәләкәч» 7 нче балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдире.